

Быел 31 январьда Республика мәдәният сараенда «Мордовия! Мин синен белән яшим», Мордовия автономиясенә нигез салынуга 95 ел тулуга багышланган тантаналы чара vтте. Республикабыз белән бергә бу олы чарада хормәтле татар милләтле халкыбыз да бәйрәм итте. Шулар арасында гомеренен кvп олешен мәгариф олкәсендә житәкчелеккә багышлаган, Инсар районы башлыгы ярдәмчесе Рауф Вәли улы Долотказин (бvләкләренен кайберләре - Почетная грамота Президента Российской Федерации, Почетный работник образования РФ, Благодарность министра образования и науки РФ, Заслуженный работник образования Мордовии) катнашты. Интервьюсында болай ди.
- Бу бәйрәм коненә Республикабыз мәдәният йортында (РДК) «Мордовия - 95! Үсеш территориясе» Мордовия Рес-публикасы Дәvләт архивы фондларыннан интерактив форматта уникаль документлар кvргәзмәсе, Сугыш һәм хезмәт батырлыгы мемориаль музее белән И.Д.Воронин исемендәге Мордовия Республика туган якны ойрәнv музее фондларыннан Боек Ватан сугышы һәм махсус хәрби операция чоры раритет экспонатлары кvргәзмәсе, СВОда катнашучыларнын портретлары кvргәзмәсе урнашкан иде. Болар барысы да Мәдәният йортынын беренче катында, ә икенчесендә - искиткеч якты палитра белән костюм, бизәнv әйберләренен этно-коллекцияләре кvргәзмәсе жәелеп ятты.
Тантаналы чара мәдәният һәм сәнгать эшлекләләре, Мордовия дәvләт филармониясенен әйдәп баручы ижат коллективлары, Мордовия дәvләт театрлары актерлары катнашында театральләштерелгән спектакльдән башланды. Прологта Мордовия автономиясенә нигез салу тарихы, мордва халкынын милли мәдәнияте һәм безнен коннәрдәге вакыйгалар чагылыш тапкан иде. Спектакльдә СВО ветераннары катнашты, алар залда тамашачыларнын алкышлары астында vз урыннарын алдылар.
Чара эчтәлекле концерт белән тәмамланды. Минем әйтәсе фикерем шул: жиребез –

борынгы гореф-гадәтле, республикамда яшәvче барлык халык-ларнын vзенчәлекле мәдәни һәм чын туганлыгы булган уникаль тобәк. Мордовия һәм Россия инде мен елдан артык бергә. Бу илебез тарихынын беренче елларыннан ук кvпмилләтле, кvпконфессияле дәvләт булуы турында дәлил. Безнен боек, жинелмәс кочебез шунда. Халыкларнын гореф-гадәтләре, мәдәнияты, ышанулары бер-берсен тулыландырып һәм баетып дус, тату яшибез.
Рауф Вәли улы ассызыклаганча, Мордовия халкы һәрвакыт Россия дәvләтчелеген яклауда һәм vстерvдә катнашкан. Анда яшәvчеләрнен кvбесе vз исемнәрен Ватаннын тарихи елъязмасына мәнгегә язып калдырган. Алар арасында - Мордовиянен изге яклаучысы, атаклы адмирал Федор Ушаков, кvренекле скульптор Степан Эрьзя, Советлар Союзы Герое, хәрби очучы Михаил Девятаев... «Минем әтием, Вәли Абдрахман улы Долотказин, Боек Ватан сугышына мәктәп скамьясыннан китеп, Курск чолганышында батырларча Ватаны очен корәшкәндә яралана - тозекләнә, тагы фронка илбасарларны тар-мар итәргә китә, тагы яралана... Боек Ватан сугышыннан дошманны жинvче булып кайта, - дип дәвам итте сvзен Рауф Вәли улы.
- Мордовия vзенен бай тарихы белән генә тvгел, бvгенге казанышлары белән дә дан тота - бу дәvләт оборона заказын vтәv дә, инновацион производствоны һәм интеллектуаль милекне vстерv дә, унайлы инвестицион климат формалаштыру да. Мәгариф олкәсенә килгәндә, Мордовиядә белем алучы киләчәк буын вәкилләребез Россиядә генә тvгел, донья кvләмендә дә беренчеләр рәтендә. Авыл хужалыгыбыздагы унышларыбыз да горурлык хисе уята. Ышанам ки, безнен бердәмлегебез һәм патриотизмыбыз белән Мордовиябезне һәм Россиябезне яна казанышлар, унышлар котә.

**Наилә НАСЫРОВА**